СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**« 11 » декабрь 2020 ел** **№ 31**

**Арча район Советының 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы "Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 23 гыйнварындагы 158 номерлы, 2019 елның 14 апрелендәге 231 номерлы үзгәрешләр белән)**

Арча муниципаль районының социаль-икътисадый, мәдәни үсешенә зур өлеш керткән өчен гражданнарны һәм предприятие, учреждение һәм оешма коллективларын бүләкләү тәртибен камилләштерү, аларның район алдындагы казанышларын тану, районның иҗтимагый тормышында хезмәтне һәм активлыкны стимуллаштыру максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

1. “Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында” Арча район Советының 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турындагы Нигезләмәгә (2018 елның 23 гыйнварындагы 158 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты турындагы Нигезләмәнең 5 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләнүгә тәкъдим ителә торган үтенечнамәдә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме паспортында рус һәм татар телләрендә бирелешләре буенча языла (татар телендә - Россия Федерациясе гражданы паспортында гражданның шәхесе турында татар телендә белешмәле кушымтасы булган очракта), вазыйфасы хезмәт кенәгәсендәге язмалар нигезендә, коллективлары бүләкләүгә тәкъдим ителә торган орган яисә оешма исеме нигезләмә, физик затның шәхси эшмәкәр буларак теркәлү турында таныклыгы, устав, органның яисә оешманың башка гамәлгә кую документы нигезендә языла»;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гражданны Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты белән бүләкләү вакытында нәтиҗәле хезмәт (кимендә 3 ел), предприятиенең, оешманың

яисә башка бүләкләүләрнең булуы, күренекле казанышларда чагыла торган аерым очраклардан тыш, мәҗбүри шарт булып тора;

в) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты тексты ике дәүләт теленең берсендә рәсмиләштерелә. Үтенечнамә Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хатын рәсмиләштерү күздә тотыла торган телдә рәсмиләштерелергә тиеш»;

2. «Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында» Арча район Советының 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы башлыгының Рәхмәт хаты бланкын (2018 елның 23 гыйнварындагы 158 номерлы үзгәрешләре белән) 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

3. Арча район Советының 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы «Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында» карары белән расланган Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турындагы Нигезләмәгә (2019 елның 14 апрелендәге 231 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Гражданны Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләклəгәндә нәтиҗәле хезмәт (кимендә 5 ел), предприятиенең, оешманың яисә башка бүләкләүләрнең булуы, күренекле казанышларда чагыла торган аерым очраклардан тыш, мәҗбүри шарт булып тора»;

б) Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы турындагы Нигезләмәнең 8 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. «Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнүгә тәкъдим ителә торган үтенечнамәдә гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме паспортында рус һәм татар телләрендәге бирелешләре буенча языла (татар телендә - Россия Федерациясе гражданы паспортында гражданның шәхесе турында татар телендә белешмәле кушымтасы булган очракта), вазыйфасы хезмәт кенәгәсендәге язмалар нигезендә, коллективлары бүләкләүгә тәкъдим ителә торган орган яисә оешма исеме нигезләмә, физик затның шәхси эшмәкәр буларак теркәлү турында таныклыгы, устав, органның яисә оешманың башка гамәлгә кую документы нигезендә языла»;

в) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы тексты ике дәүләт теленең берсендә рәсмиләштерелә. Үтенечнамә Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасын рәсмиләштерү күздә тотыла торган телдә рәсмиләштерелергә тиеш».

4. «Арча муниципаль районы бүләкләрен гамәлгә кую турында» Арча район Советының 2006 елның 10 февралендәге 44 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы башлыгының Мактау грамотасы бланкын (2019 елның 14 апрелендәге 231 номерлы үзгәрешләр белән) 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

5. Арча муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләү өчен тапшырыла торган материалларны карау буенча комиссия составына үзгәрешләр кертергә һәм аны 3 нче кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары А.Ф.Мөхәммәтовага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ


**РАСЛАНГАН**

*Арча район Советының*
*11 декабрь 2020 ел, № 31*
*карарына 1 нче кушымта*

ГЛАВА АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# РӘХМӘТ ХАТЫ



ГЛАВА АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО



**РАСЛАНГАН**

*Арча район Советының*
*11 декабрь 2020 ел, №31*
*карарына 2 нче кушымта*

ГЛАВА АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

# МАКТАУ ГРАМОТАСЫ ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА



**РАСЛАНГАН**

*Арча район Советының*
*11 декабрь 2020 ел, № 31*
*карарына 3 нче кушымта*

**Арча муниципаль районы бүләкләре белән бүләкләү өчен тапшырыла торган материалларны карау комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Нуриев Илшат Габделфәртович | - Арча муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Мөхәммәтова Алсу Фирдәвесовна | - Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Фәйзрахманова Эльвира Минзаһитовна | - башкарма комитет аппаратының гомуми-оештыру бүлеге башлыгы, комиссия секретаре (килешү буенча). |
| ***Комиссия әгъзалары:*** | |
| Гапдерахманова Гүзәл Әдһәмовна | - Арча район Советының гомуми- оештыру бүлеге башлыгы; |
| Галимуллин Радик Наилевич | - Арча район Советы аппараты җитәкчесе; |
| Мөхәррәмов Рәсүл Ринатович | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |